| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

01.02.2022 г.Лениногорск № 6

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 14 июлендәге 68 номерлы «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү турында» карары белән расланган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 14 июлендәге 68 номерлы «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү турында» карары белән расланган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлек 5 пунктның 4 абзацында «(офшор зоналар)» сүзләреннән соң «,һәм алар үзләренең табышлы сатып алучылары, бенефициар хуҗалары һәм контрольлек итүче затлар турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә мәгълүмат ачуны һәм бирүне гамәлгә ашырмыйлар;» сүзләре белән тулыландырырга;

5 абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2 бүлектәге 4 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга: «Вәкаләтле органга муниципаль милекне сату функцияләрен гамәлгә ашырырга, милекче исеменнән билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырыла

торган мөлкәтне муниципаль берәмлек милкендә сатуны оештырырга һәм (яки) мондый мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашырырга йөкләнә.»;

3 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) эшләү РФ Хөкүмәтенең 2005 елның 806 номерлы карары (2021 елның 3 ноябрендәге ред.) белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү һәм федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарларны әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары белән расланган тәртиптә гамәлгә ашырыла».

5 бүлекнең 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль милекне сату, муниципаль милекне сату буенча аукционнар һәм конкурслар муниципаль милекне хосусыйлаштыру буенча аукционнар оештыру һәм үткәрү буенча даими эшләүче комиссия үткәрә, аның шәхси составы «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия составына керәләр:

- Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасары;

- Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары.

- Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе;

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының муниципаль казна учреждениесенең җир мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесенең хокук (юридик) бүлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесенең муниципаль милек белән идарә итү һәм хосусыйлаштыру бүлеге башлыгы;

- Лениногорск муниципаль районы авыл җирлеге башлыгы.

Комиссиянең персональ составы, кирәк булганда, «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән үзгәртелә.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) крнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының бюджет, салымнар, финанслар, икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск
муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов